**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**БОЕРЫГЫ**

13.06.2023

№ 204

**Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү территориаль ярдәмче системасы идарә органнары һәм көчләре өчен югары дәрәҗәдә әзерлек режимын бетерү турында**

Татарстан Республикасы территориясендә яңа коронавирус инфекциясе (2019-nCoV) таралу куркынычы кимү һәм эпидемиологик хәл тотрыклылану белән бәйле рәвештә:

1. Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү территориаль ярдәмче системасы идарә органнары һәм көчләре өчен югары дәрәҗәдә әзерлек режимын бетерергә һәм төбәк (муниципальара) дәрәҗәсендә чаралар күрүне туктатырга.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү территориаль ярдәмче системалары идарә органнары һәм көчләре өчен югары дәрәҗәдә әзерлек режимы кертү турында» 2020 елның 19 мартындагы 129 номерлы боерыгы үз көчен югалткан дип танырга.

**Татарстан Республикасы Рәисе**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Р.Н. Миңнеханов**